ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 сентябрь, 2015 ел № 2/14

2016 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында

2015 елның 30 сентябрендәге «2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында, Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» Федераль законның 3 маддәсе гамәлдән чыгуны тану турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2016 елның 1 январенә кадәр туктатып торырга:

1) планнар чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын төзү һәм раслау, Шәһәр Советына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты белән бер үк вакытта планнар чорына документлар һәм материаллар тапшыру өлешендә (шәһәрнең социаль-икътисадый үсеш фаразыннан, бюджет сәясәтенең төп юнәлешләреннән, салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш) Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге 28/7, 2014 елның 16 октябрендәге 33/6, 2015 елның 15 апрелендәге 39/6 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәнең (алга таба – бюджет процессы турында Нигезнамә) гамәлдә булуын;

2) бюджет процессы турында Нигезнамәнең 18 маддәсе 2 өлеше беренче абзацының, 18.1 маддәсе 5, 6 өлешләренең гамәлдә булуын.

2. 2016 елда билгеләргә:

1) шәһәр бюджеты средстволарын алучы тарафыннан электән бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә 2017 елда түләнергә тиешле йөкләмәләр кабул ителгән килешүләр шәһәр бюджеты средстволарын алучы инициативасы буенча аңа бюджет йөкләмәләре

лимитын күрсәтелгән елга биреп бетермәү белән бәйле рәвештә өзелмиләр;

2) Башкарма комитет карарлары нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән чорга чыгым йөкләмәләре барлыкка килү шартын куйган килешүләр төзергә мөмкин.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев